Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Мөслим авыл җирлеге Советы

Решение Карар

2021 елның 27 сентябре №14/1

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Мөслим авыл җирлегендә җирдән
файдалану һәм төзелеш алып бару
кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 20 пункты, Чистай муниципаль районының «Мөслим авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Мөслим авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Мөслим авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 12 маендагы 9/2 номерлы Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Мөслим авыл җирлеге Советы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Чистай муниципаль районының 2014 елның 7 июлендәге 44/1 номерлы карары белән расланган Чистай муниципаль районының «Мөслим авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре III өлешенең 11 бүлегенең 35 статьясына, «Ж1. Шәхси торак төзелеше зонасы» бүлеген түбәндәге абзацлар белән өстәп үзгәрешләр кертергә:

«Җир кишәрлекләренең иң чик күләмнәре һәм рөхсәт ителгән төзелешнең чикле параметрлары, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү.

Җир кишәрлекләренең чик күләме һәм рөхсәт ителгән төзелеш, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең чик параметрлары.

| Параметрларның төрләре һәм үлчәү берәмлекләре | Күчемсез милекне файдаланунының төп рөхсәт ителгән төрләренә карата параметрларның әһәмияте | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Аерым торучы гаилә йорты | Бер гаиләгә блокланган күп гаилә йортында торак берәмлеге | Бакча лар (дачал ар) | Яшелчә бакчала ры | ЛПХ |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **Җир кишәрлекләренең иң чик параметрлары** | | | | | | |
| Минималь мәйдан | кв. м | 1000 | 1000 | 400 | 400 | 1000 |
| Максималь мәйдан | кв. м. | 2500 | 2500 | 600 | 600 | 10000 |
| Җир кишәрлекләре киртәләренең максималь биеклеге | м | 2,0* | 1,2* | 1,2* | 1,2* | 1,2* |

* Бакча биләмәләре арасындагы киртәләр материалы һәм тибы табигый яктыртуны чикләми торган материаллардан кабул ителә.

Таблицага искәрмә

Искәрмә 1. Фактта файдалану Россия Федерациясе Җир кодексы үз көченә кергән көнгә кадәр булган һәм җир кишәрлеге мәйданын нормативка кадәр киметү яисә арттыру мөмкинлеге булмаган җир кишәрлегенең чик параметрлары күрсәткечләреннән таблицада тәкъдим ителгән чик параметрлардан тайпылу рөхсәт ителә.

Искәрмә 2. Мөслим авыл җирлеге чикләрендә урнашкан, өч һәм аннан күбрәк бала, шул исәптән үги улларын, үги кызларын, шулай ук унсигез яшькә җитмәгән уллыкка (кызлыкка) һәм тәрбиягә алынган балаларны (аларга карата опека һәм попечительлек вакыты чикләнмәгән йә алар балигъ булганчыга кадәр гамәлгә ашырыла) җир кишәрлеге милкенә бирү (тапшыру) турында гариза бирелгән датага Чистай муниципаль районы территориясендә даими яшәүче гражданнарга бирелә торган җир кишәрлекләренең иң чик күләме:

- индивидуаль торак төзелешен гамәлгә ашыру өчен, дача төзелеше, бакчачылык яисә яшелчәчелек өчен - 700 кв.метрдан 900 кв.метрга кадәр;
- шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен (йорт янындагы җир кишәрлеге 1000 кв.м дан 1500 кв.м га кадәр)».

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең торак пунктлары территориясендә махсус мәгълүмат стендларында яисә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә, шулай ук Чистай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

Мөслим авыл җирлеге
башлыгы Л.З. Хәбибуллина